ДҮШӘМБЕ
15 ГЫЙНВАР
1940 ел
№ 12 (5812)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

Москва, ВКП(б) Үзәк Комитеты— иптәш СТАЛИНГА. СССР Совнаркомы— иптәш МОЛОТОВКА.

Хәрәкәттәге „Георгий Седов“ бозваткыч пароходын Гренландия диңгезе бозларыннан чыгару буенча Сезнең заданиегезнең беренче өлеше үтәлде. 1940 нчы елның 13 нче гыйнварында 12 сәгат 07 минутта „И. Сталин“ бозваткычы „Георгий Седов“ бозваткыч пароходының бортына якын килде. Пароход экипажының барлык членнары сәламәтләр. Заданиенең икенче өлешен үтәүгә керештек.

СССР Халык Комиссарлары Советы янындагы Главсевморпути начальнигы И. ПАПАНИН.

„И. Сталин“ бозваткычы борты, Гренландия диңгезе.

МОСКВА, КРЕМЛЬ.

ИПТӘШ СТАЛИНГА

Бүген, 13 нче гыйнварда, 12 сәгат 07 минутта Арктика флоты флагманы „Иосиф Сталин“ бозваткычы, партиянең һәм хөкүмәтнең заданиесен үтәп, безнең карабның бортына якын килде. „Седов“ның 812 көн дәвам иткән хәрәкәте тәмам булды.

Безне бозлар пленлегеннән коткару өчен сөекле Ватаныбыз, партиябез, хөкүмәтебез һәм, иптәш Сталин, Сезнең үзегез тарафыннан Арктиканың югары киңлекләренә җибәрелгән совет кешеләре белән без, гаять зур шатлык хисе шартларында очраштык. Бөтен хәрәкәт дәвамында Сезнең, кадерле Иосиф Виссарионович, һәр вакыт кайгыртучанлык күрсәтүегезне сиздек. Бозлар арасында булуыбызның яхшы тәмам булачагына ышаныч безне бер генә минутка да ташламады. Безне бер нинди куркынычлар да куркытмадылар, һәр вакыт ярдәм итәргә хәзер торган куәтле Ватаныбызның безне күзәтеп торганлыгын без белеп тордык.

Сезнең исмегез, иптәш Сталин, иң авыр минутларда безне рухландырды, Сезнең исмегез белән без теләсә нинди авырлыкларны җиңүгә бардык һәм аларны җиңдек. Рәхимсез стихиянең бөтен ударларына да карамастан сакланып калган карабыбызда Ватанга әйләнеп кайтабыз. Без тулы көчләр белән һәм Ватанның бәхте өчен, фәнебезнең файдасы өчен, җиңелүләрне белми торган большевиклар партиясе файдасы өчен эшләргә хәзер торган хәлдә Зур Җиргә әйләнеп кайтабыз. Сезгә ялкынлы сәлам һәм кайгыртучанлыгыгыз өчен, туганыбыз Иосиф Виссарионович, бик зур рәхмәт!

„Седов“ экипажы: ***Бадигин, Мегер, Шарыпов, Гаманков, Буторин, Трофимов, Полянский, Ефремов, Буйницкий, Алферов, Бекасов, Соболевский, Гетман, Токарев, Недзвецкий.***

ГЕРОЙ СЕДОВЧЫЛАРГА ДАН

Унөченче гыйнварда эфир дулкыннары котып баһадиры Иван Дмитриевич Папанинның: „И. Сталин“ бозваткычы „Седов“ янына килеп җитте“ дигән хәбәрен бөтен җир йөзенә тараттылар.

Яңа җиңү турында беренче сүз, беренче рапорт Москвага, Кремльгә—Сталинга җибәрелде: „Хәрәкәттәге бозваткыч „Седов“ пароходын Гренландия диңгезе бозларыннан чыгару буенча сезнең заданиегезнең беренче өлеше үтәлде... Заданиенең икенче өлешен үтәүгә керешәбез. Папанин“.

Бу шатлыклы хәбәрне безнең ил, бөтен прогрессив кешелек дөньясы соңгы көннәрдә сәгат саен, минут саен көтте. Данлыклы ике карабның бергә килүе турындагы, героик экипажларның тарихи очрашулары турындагы хәбәр безне, безнең сөекле Ватаныбызның данын тагын да югары күтәрде. Илебезнең халкы чын магнәсе белән шатлыкка, данга чумды!

Очсыз-кырыйсыз котып диңгезендә, боз ярлары арасында егерме алты ай буена сузылган тиңдәшсез хәрәкәт тәмам булды. Безнең илнең гади кешеләре, батыр уллары Бадигиннар, Трофимовлар, Буйницкилар, Полянскилар, Шарыповлар күрсәткән хезмәт, аларның стихиягә каршы көрәшләре һәм фән хәзинәсен яңа казанышлар белән тулыландырулары рәхимсез котыпны яулап алу көрәшенең иң гүзәл, иң мактаулы сәхифәсе булачак, бу батырлыкны фән дөньясы, кешелек дөньясы бер кайчан да онытмас! Алар хезмәтен кешеләр мәңге истә тотарлар, мәңге ихтирам итәрләр! Аларга дан, аларга иң тирән хисләрдән чыккан ялкынлы сәлам!

Совет кешеләре батырлыкны, геройлыкны, данлыкны бер исем белән—бөек Сталин исеме белән яулап алалар. „Седов“ экипажының шөһрәт казануы, аның чиксез зур фәнни эше, котыпның әлегә кадәр кеше көче белән ачылуы мөмкин булмаган тирән серләрен ачу, аларны социализмга хезмәт иттерергә буйсындыру тик безнең илдә генә, Сталин җитәкчелегендә генә мөмкин булды. Ленин—Сталин эшенә чын күңелдән бирелгәнлек седовчыларны һәр төрле куркынычларны да җиңеп чыгарга рухландырды. „Седов“ карабындагы коллективның, боз диңгезе пленендә калган шушы кечкенә семьяның—совет семьясенең һәрбер кешесе—ул бөек СССР ның ялкынлы патриоты, ул үзенең һәрбер казанышы социализмның яңа җиңүенә хезмәт итүне ачык белүче.

...„Сезнең исмегез, иптәш Сталин, иң кыен минутларда да безне рухландырды, без Сезнең исмегез белән теләсә генә нинди кыенлыкларны да җиңәргә бардык һәм аларны җиңдек“. Седовчылар Папаниннар белән беренче очрашу тойгысында иптәш Сталинга язган радиограммада әнә шулай диләр.

Әйе, бу яңа, бу зур җиңү дә бөек остазыбыз, туганыбыз Сталин исме белән бәйләнгән. Күз ачмаслык көчле котып бураннарында да, дәһшәтле боз таулары ишелеп килгәндә дә, котырган диңгез өстендәге караб йомычка шикелле чайкалганда, караб стеналары бозлар һөҗүменнән, бозлар кысудан шытырдаган чакта да алар, седовчылар, Сталинга булган мәхәббәт белән, Сталин күрсәткән кайгыртучанлык белән җылылык таптылар. Үзләрен ил белән бергә хис иттеләр. Алар шундый штурм вакытларында фәнни эшләр алып бардылар, тагын да зуррак җиңүләргә ирешү өчен марксизм-ленинизмны „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н өйрәнүне дәвам иттерделәр. Сабырлык белән, җиңүләренә зур ышанычлык белән алга бардылар. Бу тиңдәшсез хәрәкәт уңышлы тәмам булды. „И. Сталин“ бозваткычы „Седов“ янында. Алдагы юл— Мурманск—Ленинград—Москва—Кремль!

Седовчылар тормышының икенче этапы башланды. Бөтен ил Сезне, кадерле иптәшләр, „Седов“ геройларын көтә! Ватаныбызның һәрбер кешесе Сезне кочар өчен үзенең куйнын ача; Сезнең фәнни хезмәтләрегезне эшкәртү өчен галимнәр лаборатория ишекләрен ачалар; Сезнең батырлыгыгыз алдында миллионнар баш ия; Ватаныбыз чикләренең данлыклы һәм җиңелмәс сакчылары Сезнең геройлыгыгыз белән тагын да дәртләнәләр!

Чын культура өчен көрәш алып баручы, фән казанышларын хезмәт ияләренең ирке һәм бәхте өчен хезмәт иттерергә көрәшүче һәм бу көрәштә һаман саен алга баручы Советлар Союзы үзенең чираттагы тантанасын үткәрә, бу җиңүнең геройларын үз кочагына көтә!

Тиздән күрешүгә чаклы, седовчы иптәшләр!

Сталин исме белән алга, яңа җиңүләргә!



Художник Г. Поляков фотомонтажы.

БАТЫР КОТЫПЧЫЛАРНЫ БӨТЕН ИЛ КОТЛЫЙ!

ИЛ ГЕРОЙЛАРГА КУЛ ЧАБА

Ватаныбызның куркусыз 15 улы Арктиканың авыр бозлары арасында хәрәкәттәге карабта 800 көннән артык вакыт үткәрделәр һәм Сталин эпохасы кешеләренең, бөек большевиклар партиясе һәм иптәш Сталин тәрбияләп үстергән кешеләрнең нәрсәләргә сәләтле икәнлекләрен бөтен дөньяга күрсәттеләр.

Арктиканың кыю геройларына, безнең седовчыларга бер нинди киртәләр дә, бер нинди кыенлыклар да куркыныч булмады. Алар Арктиканың мәкерле стихиясенә каршы көн саен ныклы көрәш алып бардылар, каты салкыннарга, буранга, томанга, котып караңгылыгына карамастан, гаять зур әһәмиятле фәнни эшне салкын канлылык һәм тәртип белән башкардылар. Үзләренең зур хезмәтләре белән седовчылар яңа материаллар таптылар һәм фәнне баеттылар.

15 батыр совет кешесенә бөтен Ватаныбыз кул чаба. Үзләренең батырлыклары белән совет халкының данын арттырган ватандашларының илебезгә кайтуларына һәрбер совет гражданы чиксез шат.

Седовчыларның легендар хәрәкәте геройлыкка, батырлыкка һәм Сталин тәрбияләп үстергән кешеләрнең тимердәй ныклыгына тулы булган онтылмаслык сәхифә булып тарихка керер. Яш буын седовчылардан ничек җиңәргә, сөекле Ватаныбыз тапшыра торган эш өчен ничек көрәшергә кирәклеккә өйрәнер.

В. К. Коккинаки.
Советлар Союзы Герое.

ВАТАНЫБЫЗНЫҢ БАТЫР УЛЛАРЫНА СӘЛАМ!

(13 нче гыйнварда кич белән Москваның Сталин исемендәге автозавод цехларында кабул ителгән резолюция)

Без Арктика флоты флагманы „И. Сталин“ бозваткычының героик „Седов“ бозваткычы экипажы белән очрашуы турында радио буенча тапшырылган хәбәрне гаять зур шатлык белән каршыладык.

Без бөек Ватаныбызның байрагын рәхимсез Арктика киңлекләрендә горур рәвештә йөрткән легендар геройларга—седовчыларга чын күңелдән сәлам тапшырабыз. Без барлык кыенлыкларны батыр төстә җиңгән һәм „Г. Седов“ бозваткычын бозлардан чыгару турында илебездәге халыкларның һәм иптәш Сталинның үзенең заданиесен үтәгән „И. Сталин“ бозваткычы экипажына сәлам тапшырабыз.

Яңа елга каршы безнең завод коллективына җибәрелгән радиограммада седовчылар үзләренең тарихи хәрәкәтләренең соңгы этапында партия һәм хөкүмәт заданиесен намус белән үтәүләре турында язганнар иде. Илнең һәм иптәш Сталинның үзенең кайгыртучанлыгы белән җылытылган хәлдә алар хәзер юлларының соңгы этапын уңышлы рәвештә тәгәллиләр.

Сәлам сезгә, Ватаныбызның батыр уллары!

Сезне үзебезнең кызыл башкалабызда — Москвада түземсезлек белән көтәбез.

Яшәсен җиңүләребезне рухландыручы, остазыбыз һәм дустыбыз бөек Сталин! (ТАСС).

„СЕДОВ“ БОЗВАТКЫЧ ПАРОХОДЫ— БАДИГИНГА, ТРОФИМОВКА

„Седов“ бозваткыч пароходының героик хәрәкәтенең уңышлы тәмам булуына чиксез дәрәҗәдә шатланабыз. „Седов“ның данлыклы экипажына большевистик сәлам. Кызыл башкалага тиз арада кайтып керүегезне бөтен совет халкы белән берлектә, әйтеп бетерә алмаслык шатлык белән көтәбез.

Сезне нык һәм нык кочаклыйбыз.

Ширшов Стреколовский
Белахов Кренкель
Шевелев Задоров
Мазурук.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

13 нче гыйнварда Ухта һәм Реболы юнәлешләрендә разведка партияләре хәрәкәт итте. Петрозаводск юнәлешендә пехота частьләренең бәрелешләре дәвам итте. Карелия бугазында разведчикларның эзләнүләре һәм кайбер участкыларда сирәк-сирәк артиллерия атышуы булды.

Безнең авиация тимер юл узелларында һәм сугыш объектларында урны-урны белән күп кенә бомбардировка операцияләре үткәрде.

КРАСИНЧЫЛАР СЕДОВЧЫЛАРНЫ КОТЛЫЙЛАР

ВЛАДИВОСТОК, 13 гыйнвар. (ТАСС). Орденлы „Красин“ бозваткычы экипажы „Седов“ның хәрәкәтен зур игтибар белән күзәтеп торды. „И. Сталин“ бозваткычының батыр седовчыларга таба баруы турындагы телеграммалар дулкынлану белән укылды. Красинчылар батыр капитан иптәш К. С. Бадигин җитәкчелегендәге седовчылар белән горурланалар. Бу аңлаешлы да. Иптәш Бадигин „Красин“ бозваткычында тәрбияләнде. Монда ул Арктика диңгезләре штурманы булып практик эш башлады, көч җыйнады һәм Арктиканың рәхимсез диңгезләрен җиңәргә өйрәнде.

„Красин“ бозваткычы капитанының өлкән ярдәмчесе иптәш Сагайдак болай ди:

— 1937 нче елны „Красин“, Арктиканың көнчыгыш секторында суднолар озатуны тәмам итеп, „Садко“ һәм „Седов“ бозваткычларына ярдәмгә барды. Иптәш Бадигин бу рейстә катнашмады, чөнки ул отпускта иде. Бозваткыч „Садко“га бөтенләй диярлек якынлашкач, мин боз өстеннән безгә таба бер кеше йөгереп килгәнлекне күрдем. Йөгерүче кешенең иптәш Бадигин икәнлеген күргәч красинчылар гаҗәпләнделәр.

Бадигинның иптәшләре:

— Отпускага китте, ә үзе Арктикада. Җирдә утыра алмас кеше!—дип шаярдылар.

Шул вакытта ул „Садко“га капитанның икенче ярдәмчесе итеп билгеләнде.

Красинчылар батыр седовчыларга һәм аларның данлыклы капитаны иптәш К. С. Бадигинга чын күңелдән туганнарча сәлам җибәрәләр.

МУРМАНСКИЙ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ГЕРОЙ СЕДОВЧЫЛАРНЫ КАРШЫЛАРГА ХӘЗЕРЛӘНӘЛӘР

МУРМАНСКИЙ, 13 гыйнвар. (ТАСС). Арктика флоты флагманы „И. Сталин“ бозваткычының соңгы боз барьерын җимереп легендар „Г. Седов“ бозваткычына якынаюы турындагы хәбәрне Мурманский хезмәт ияләре зур шатлык белән тыңладылар. Советлар Союзы Герое И. Д. Папанин экспедициясенең батыр седовчылар белән очрашуы турындагы хәбәр караңгы котып төнендә чорналган шәһәрдә телдән-телгә күчеп йөри.

Тимер юлчылар, балыкчылар, сәүдә һәм Арктика флоты моряклары куркусыз седовчыларның батырлыклары турындагы беседаны зур кызыксыну белән тыңлыйлар. Заводларның кызыл почмакларында, Кола елгасы яйласында урнашкан мастерскойларда, зур кыя таулар белән чолгап алынган һәм тыңмый торган тар фиорд буйларында йөзләрчә агитаторлар көн саен эшчеләрне җыеп, аларга Папанин, Ширшов, Федоров мәкаләләрен укыйлар, Советлар Арктикасын үзләштерү өчен көрәш тарихына гүзәл сәхифәләр язган 15 героик котыпчының гүзәл эшләре турында Бадигинның радиограммаларын укыйлар.

Бөтен шәһәр, барлык предприятиеләр, учреждениеләр, мәктәпләр седовчыларны каршыларга хәзерләнәләр. Седовчылар өчен махсус билгеләнгән квартираларга ремонтлар ясала. Культура йортында художниклар 15 котыпчы геройның портретларын ясыйлар, портны бизиләр. Бозваткычлар килгән көнне монда күп кеше катнашы белән митинг булачак. Бозваткычлар портка кергәндә портта торучы суднoларга төрле флаглар эленәчәк. Алар легендар бозваткычны котлау салютлары белән каршылаячаклар.

Бүген партиянең Киров райкомы бюросы Мурманский шәһәр Советы депутатлары булган седовчыларның үз сайлаучылары белән очрашуларны оештыру турында карар кабул итте.

Эшчеләр, моряклар, кызыл армеецләр, укытучылар, хезмәткәрләр седовчыларга бүләкләр хәзерлиләр.

ГЕРОИК ЭКИПАЖГА ЯЛКЫНЛЫ СӘЛАМ!

СССР Фәннәр Академиясе „Седов“ның героик экипажын боз өстендә тарихта тиңдәше булмаган хәрәкәтне уңышлы хәл итү уңае белән чын күңелдән котлый. Бу хәрәкәт фәнне гаять зур әһәмиятле мәгълүматлар белән баетты һәм ул бөтен алдынгы кешелек дөньясының урынлы шатлануын һәм ихтирамын тудырды.

СССР Фәннәр Академиясе президиумы, академиклар: В. Л. Комаров, О. Ю. Шмидт, Е. А. Чудаков, А. Н. Бах, В. П. Никитин, А. М. Деборин, П. И. Степанов, В. Н. Образцов.

(ТАСС).

РӘСЕМДӘ: „Седов“ бозваткычын бозлар арасыннан чыгару эшен алып баручы И. Д. Папанин һәм „Иосиф Сталин“ бозваткычы капитаны М. П. Белоусов иптәшләр.

Д. Дебабов фотосы (ТАСС фото-клишесе).

СОВЕТ КЕШЕСЕ КУӘТЛЕ

Бөек илебезнең данлыклы һәм мактаулы уллары Сезгә кайнар сәлам!

Сталин эпохасындагы совет кешеләренең искиткеч батырлыклары законлы рәвештә бер-бер артлы булып тора. Сез дөньяга тиңдәшсез эшләр күрсәтәсез, сез данлыклы Арктика эпопеясен куркусыз төстә һәм зирәк эш белән тәгәллисез. Куәтле совет кешесе—социалистик Ватан улы сезнең йөзегездә стихияне җиңә һәм аның өстеннән властьлык итә. Сез табигатьнең серләрен бер-бер артлы чишәсез һәм тиңдәшсез кыюлыклар эшлисез һәм аларны тормышка ашырасыз.

Мондый улларны тудыручы халык бөек. Кешеләренең энтузиазмы партия, хөкүмәт һәм бөек юлбашчыбыз иптәш Сталин бурычларын аяусыз төстә хәл итеп фән, техника өлкәсендә геройлык эшләре күрсәтүче ил бәхетле.

Ватаныбызның бөеклеген һәм бәхтен нығытуыгыз өчен сезгә тирәнтен рәхмәт хисе белдерәбез. Аның күп миллионлы халкы үзенең фикерләре һәм хисләре белән сезнең белән берлектә һәм сезнең уңышларыгыз өчен чиксез бәхетле. „И. Сталин“ бозваткычынын „Г. Седов“ бозваткычы белән котып төне илендә очрашуы совет фәне һәм бөтен дөнья фәне тарихында мәңгегә якты сәхифә булып калыр. Зур Җиргә сезнең тиздән һәм бәхетле рәвештә кайтуыгызны телим.

Академик **Н. Бурденко.**
СССР Верховный Советы депутаты.

СОВЕТ БОЗВАТКЫЧЛАРЫН ТӨЗҮЧЕЛӘР ДАНЛЫКЛЫ КОТЫПЧЫЛАРНЫҢ БАТЫРЛЫКЛАРЫНА СОКЛАНАЛАР

Ленинградның Серго Орджоникидзе исемендәге судноплар төзү заводы коллективы, бөтен совет халкы белән берлектә совет котыпчыларының—„Г. Седов“ һәм „И. Сталин“ бозваткычларының гүзәл экипажларының геройлыкларына, батырлыкларына, куркусызлыкларына сокланалар.

Без, судно төзүчеләр, седовчыларны боз пленлегеннән коткарган Арктика флоты флагманы „И. Сталин“ бозваткычының безнең заводта эшләнгән булуы белән горурланабыз. Без, балтыйкчылар, аны ерак рейскә җиһазладык, аны алдынгы техника белән кораллandырдык. Бу техника папанинчылар кулында Арктиканың рәхимсез стихиясен уңышлы рәвештә җиңде.

Героик хәрәкәт тәгәлләнде.

Кадерле иптәшләр, бөек совет халкының батыр улларын үзебезнең заводта—„И. Сталин“ бозваткычы ясалган урында үзебез котлау өчен сезнең Зур Җиргә кайтуыгызны түземсезлек белән көтәбез.

Ленинградның Серго Орджоникидзе исемендәге судноплар төзелеше заводының эшчеләр, инженерлар, техниклар һәм хезмәткәрләр коллективының тапшыруы буенча:

*Директор—**Товстых.***
*Партком секретаре—**Воробьев.***
*Завком председателе—**Лейкин.***

Ленинград, 13 гыйнвар. (ТАСС).

Үз-үзләрен аямаучы патриотлар

„Седов“ бозваткычының героик экипажын чын күңелдән котлыйм. Совет кешеләренең большевистик ныклыгы белән, озак һәм кыен юлның бөтен читенлекләрен җиңеп, ул, Ватанга җиңүче булып әйләнеп кайтыр.

Седовчылар—чын-чыннан совет патриотлары. Аларның яхшылыклары һәм батырлыклары, бөек ватанга чын күңелдән бирелгәнлекләре—партияле һәм партиясез большевикларга хас булган сыйфатлар. „Седов“ экипажының патриотизмы бөтен совет халкының какшамас теләгеп һәм куәтлелеген, аның мораль-политик бердәмлеген, Ленин—Сталин партиясе тирәсенә тупланганлыгын чагылдыра.

„Седов“ бозваткычы хәрәкәтенең фәнни әһәмияте гадәттән тыш зур. Караб әлегә кадәр тирәнлекләрне үлчәү өчен Океан төбенә герле бау төшерелмәгән, магнит һәм метеорология күзәтүләре үткәрелмәгән районнарда булып үтте. Седовчылар чиксез энергия белән, армый-талмый эшләделәр, үзләренең күзәтүләре турында радио аша системалы рәвештә хәбәр биреп тордылар.

Куркусыз моряклар булган седовчыларның исемнәре тарихка алтын хәрефләр белән язылыр. Бөтен хезмәт иясе кешелек дөньясының культура һәм прогресс таянычы булган илебез киләчәктә дә андый кешеләр белән бөтен дөнья күләмендә әһәмиятле булган күп җиңүләргә ирешер.

Үз—үзләрен аямаучан патриотларга—седовчыларга дан!

В. А. Дегтярев.
Социалистик хезмәт батыры.
(ТАСС).

ТИҢДӘШСЕЗ БАТЫРЛЫК

„И. Сталин“ флагман бозваткычы белән „Седов“ның героик очрашуы турындагы хәбәрне Советлар Союзының хезмәт ияләре гаять зур шатлык белән каршы алдылар.

Седовчыларның тиңдәшсез батырлыклары—үз Ватанының заданиесен иң авыр шартларда, батырларча башкарып чыккан совет кешеләренең гүзәл сыйфатларын күрсәтә торган яңа күрсәткеч. Бу сыйфатлар—большевистик ныкторучанлык, хезмәттә ныклык, үз эшенә ышану һәм Ленин—Сталин партиясе эшенә чиксез бирелгәнлек.

Шулай ук без совет судно төзүчеләре тарафыннан төзелгән Арктика флоты флагманы „И. Сталин“ бозваткычы экипажының гүзәл эше белән горурланабыз.

Рәхимсез Арктиканың авыр шартларында „И. Сталин“ бозваткычы 3 метр калынлыгындагы бозларны уңышлы рәвештә җиңде һәм 10 мең ат көченд әге бөтен куәте белән алга юл салды. Гаять нык итеп төзелгән карабның корпусы зур сынау алдында булды.

„И. Сталин“ бозваткычы—безнең иң зур һәм иң куәтле бозваткычыбыз. „И. Сталин“ бозваткычының уңышы бер үк вакытта бу карабны проектлаштыручы конструкторларыбызның — судно төзүчеләребезнең һәм бу бозваткычны төзегән Балтык судно төзелеше заводы эшчеләре, инженерлары һәм техниклары коллективының уңышы булып тора.

„И. Сталин“ бозваткычының „Седов“ бозваткычы белән очрашуының шатлыклы моментында судно төзүчеләр коллективы аларның героик экипажларына үзенең большевистик сәламен җибәрә.

И. Тевосян.
СССР Судноплар Төзелеше Промышленносты Халык Комиссары.

Хәрәкәттәге карабта 26 ай

АРКТИКАДА ҖӘЙ

28 нче мартта седовчылар төн уртасы кояшын күрделәр: седовчылар иллюменаторларны ачтылар. Унбиш батыр Ватанның даны өчен үзләренең эшләрен тагын да зуррак энтузиазм белән дәвам иттерделәр. Арктикада башланган Котып көне фәнни эшләрне киңәйтергә мөмкинлек бирде. Бозларны өйрәнүгә, хәрәкәтнең юнәлешен билгели торган агымнарны һәм җилләрне күзәтүгә седовчылар аеруча зур игтибар бирделәр.

9 нчы июньдә „Седов“ 86 нчы параллельне өченче тапкыр аркылып чыкты һәм авыр бозлар белән берлектә, бөтенләй диярлек „Фрам“ юлы белән параллель юнәлештә, ләкин аңардан төньяктарак хәрәкәт итә башлады.

Арктикада җәй башлану белән „Седов“ тирәсендә зур ярыклар күренде. Җылылык башлану „Седов“ экипажына, фәнни эшләрне туктатмыйча, үзенең пароходын тәртипкә китерү эше белән шөгыльләнү мөмкинлеген бирде. Бозваткычның командасы пароходка ремонт ясау өчен берничә группага бүленде. Корпустагы тутыклар бетерелде, коррозия белән аеруча нык зарарланган урыннар буялды, палуба механизмнарына ремонт ясалды, төп машина бер кадәр сүтелде һәм казаннар чистартылды. Июннең егерменче көннәрендә седовчылар зур җиңүгә ирештеләр: бозваткычның 1938 нче елның августында зарарланган руленә аларның героик көчләре белән ремонт ясалды. Рульне һәм ахтерштевенны төзәтү, рульне нығыта торган бөтен системаны төзәтү белән седовчылар карабны яңадан үзләре теләгәнчә йөртү мөмкинлеге алдылар: „Седов“, бозваткыч артыннан үзлегеннән бара алырлык хәлгә килде.

Августның икенче яртысында „Седов“ хәрәкәт итә торган районда көннәр суытты. Өченче Котып төне башланды, өченче Котып кышлавы якынлашты.

29 нчы августта „Седов“ бөтен хәрәкәт вактында иң зуры булган төньяк киңлекнең 86 градус 40 минутына җитте. Төньяк Боз океаны суының Гренландия диңгезе юнәлешенә таба даими агымы хәрәкәтнең тизлегенә һәм юнәлешенә тәэсир итә башлады.

Норвегия пароходы „Фрам“ га караганда шактый төньяктарак һәм шактый тизрәк хәрәкәт итә торган легендар совет бозваткычы „Седов“ 1939 нчы елның 23 нче октябрендә, „Фрам“ юлыннан бер кадәр көньяккарак һәм көнчыгышкарак, чама белән, 1937 нче елның 23 нче октябрендә „Төньяк Котып“ станциясе булган киңлектә булды. Куәтле агым карабны Гренландия белән Шпицберген арасындагы проливка алып китте.

„СЕДОВ“ ТА БӘЙРӘМ

Седовчылар хәрәкәтнең икенче еллыгын шатлыклы рәвештә бәйрәм иттеләр. Алар бу көнне капитан Бадигин һәм помполит Трофимов иптәшләр исменә Сталин һәм Молотов иптәшләр имзасы белән җибәрелгән радиограмманы гаять зур тәэсирләнү белән укыдылар:

„Хәрәкәтнең икенче еллыгы көнендә „Седов“ ның бөтен экипажына большевистик сәлам җибәрәбез. Сезгә сәламәтлек, барлык авырлыкларны уңышлы җиңүегезне, Арктиканың кыенлыкларына каршы көрәштә чыныгучылар булып Ватаныбызга кайтуыгызны телибез. Кулларыгызны кысабыз, иптәшләр!“.

Шул ук көнне Михаил Иванович Калинин аларны радио буенча котлады. Арктиканың югары киңлекләрендә яшәүче һәм эшләүче батыр Совет Котып моряклары икенче еллык көнендә уннарча котлау телеграммалары алдылар.

Арктика бозлары арасында хәрәкәт иткән ике ел вакыт эчендә „Георгий Седов“ бозваткычы 2.750 мильдән артык юл үтте. Аның экипажы бик зур фәнни эшләр эшләдә. Үзлегеннән хәрәкәт итү моментыннан—1938 нче елның 30 нчы августыннан бирле генә дә седовчылар тарафыннан 60 магнит пунктлары билгеләнде, магнит авышуы вариациясенә ун тәүлек күзәтүе ясалды, 47 гравитацион күзәтү башкарылды, тирән су төбеннән, сынау өчен 35 тапкыр су алынды. 26 тапкыр океанның тирәнлеге үлчәнде—грунтның үрнәкләре алынды, 5016 тапкыр метеорология күзәтүләре башкарылды. Седовчылар һәр көнне диярлек пароходның координатларын билгеләделәр. Метеорология күзәтүләрен башлангыч эшкәртү буенча гаять зур эшләр үткәрелде: хәрәкәт районындагы һава турында тәүлеккә 4 тапкыр регуляр рәвештә Москвага сводкалар бирелде.

Хөкүмәт, 15 героик котыпчыны бозлар тоткынлыгыннан алып чыгарга кирәк була калса дип Франс-Иосиф җирендә авыр самолетны хәзерлек хәлендә тотарга күрсәтмә бирде. Экспедиция өчен, 1938 нче елның башында „Седов“ ка инде бер рейс ясаган 4 моторлы „СССР—Н—171“ һава карабы билгеләнде. Седовчылар өчен авария запасы алып, авыр йөк төягән машина 1939 нчы елның 21 нче мартында Москва аэродромыннан күтәрелде һәм төньякка юнәлде. Аның экипажы, хәрәкәт итә торган карабтан беренче тревога сигналы алыну белән үк ерак Арктикага очып китәргә хәзерлек хәлендә торып, Рудольф атавында вахта алып барды.

Хәрәкәтне игтибар белән күзәтеп торучы иптәш Сталин Төньяк Диңгез Юлы Баш Идарәсе начальнигы Советлар Союзы Герое иптәш И. Д. Папанин белән очрашканда, „Седов“ка ярдәмче экспедиция җибәрергә кирәклекне әйтте.

— Вакытны үткәрмәскә, барсын да вактында эшләргә кирәк,—диде иптәш Сталин.

„СЕДОВ“ КАРШЫСЫНА

...Бозлар белән чолганып алынган хәрәкәттәге караб, 1939 нчы елның ноябрендә Шпицберген меридианын үтте һәм юнәлешне көньякка таба кискен рәвештә үзгәртте. 3 нче декабрьдә бозда беренче ярылулар күренде, алар бозваткычның чиста су районына якынлашканын хәбәр иттеләр. 7 нче декабрьдә бозлардагы ярыкларның киңлеге 250 метрга кадәр җитте. 8 нче декабрьдә инде пароход бер квадрад километр чамасы зурлыктагы боз кыры янында тора иде. Хәрәкәтнең тизлеге бик тизлек белән артты. 3 нче декабрьдән 10 нчы декабрьгә кадәрге вакыт эчендә бозваткыч, озынлык буенча үзенең торышын үзгәртмичә, көньякка таба 25 миль алга китте. Моннан соңгы билгеләр бозваткычның тиздән чиста суга чыгачагын раслады лар. Хөкүмәт хәрәкәттәге „Георгий Седов“ карабын каршы алырга куәтле бозваткычны—Арктика флотының флагманы „Иосиф Сталин“ ны җибәрергә карар бирде.

15 нче декабрьдә иртән 10 сәгаттә линейный бозваткыч „Иосиф Сталин“ Мурманскидан чыгып китте. Бозваткыч бөтен йөзү вактында кирәкле булган барлык нәрсәләр белән тулысынча тәэмин ителде. Аның бортында катлаулы Арктика кышы шартларында очу өчен җиһазландырылган самолетлар. Карабны Арктика флотының иң яхшы капитаннарыннан берсе, сыналган моряк иптәш Белоусов алып бара. Экспедициягә Советлар Союзы Герое иптәш И. Д. Папанин җитәкчелек итә.

...„Седов“ бозваткычында тормыш үз чиратында дәвам итте. Аның экипажы машиналарны тулы хәзерлек хәленә китерде, йөкне походтагыча палубага һәм трюмнарга хәзерләп куйды. 21 нче декабрьдә хәрәкәттәге карабта иптәш Сталинның 60 еллыгына багышланган җыелыш булды. Бу җыелышта „Седов“ның экипажы гаять зур күтәренкелек белән, бөтен хәрәкәт буена аталарча кайгыртучанлык һәм игтибар күрсәткән кешегә котлау телеграммасы кабул итте.

24 нче декабрьдә героик экипаж, Советлар Союзының күп миллионлы бөтен халкы белән берлектә, үзләренең тавышларын коммунистларның һәм партиясезләрнең Сталинчыл блогы кандидатларына бирделәр.

ХӘРӘКӘТНЕҢ АХЫРЫ

Яңа елны „Георгий Седов“ бозваткыч пароходының экипажы авыр бозлар арасында каршылады. Үзенең яңа ел котлавында „Седов“ бозваткычы экипажы болай дип язды:

„1939 нчы елның ахыры һәм 1940 нчы елның башы седовчыларга бозлар арасындагы хәрәкәтне тиздән тәмам итүне алып киләләр. Бөтен хәрәкәт дәвамында без, совет фәненә, Арктиканы үзләштерү эшенә кыйммәтле хәзинә булган зур фәнни эш үткәрдек. 1940 нчы яңа елны бозлар арасында һәм Котып төнендә каршылаганда без, үзебезнең беренче бокалыбызны бөтен бөек Совет халкы белән берлектә, халыкларның даһи юлбашчысы, сөеклебез, туганыбыз Сталин өчен күтәрәбез. Без үзебезнең казанышларыбыз өчен аның көндәлек кайгыртучанлык һәм игтибар күрсәтүенә бурычлыбыз. Социализм иленең бөек халкына чын күңелдән яңа ел сәламе җибәрәбез һәм котлыйбыз. Яңа җиңүләр һәм казанышлар, стахановчыл яңа рекордлар, бәхетле һәм шатлыклы тормыш телибез“.

Декабрьнең соңгы декадасында „Седов“ 72 миль хәрәкәт итте. Бу вакыт эчендә седовчылар пароходны бозлар арасыннан алып чыгуга хәзерләү буенча зур эш үткәрделәр, пичләргә ут кабыздылар, кечкенә казанда пар күтәрделәр. „Седов“ өстендә кара төтен күтәрелде.

Седовчылар бозлар арасындагы хәрәкәтнең соңгы көннәрендә һәр ике сәгать саен диярлек „Иосиф Сталин“ бозваткычы белән сөйләштеләр.

...Авыр бозлар аркылы „Иосиф Сталин“ хәрәкәттәге караб янына барды.

...15 батыр совет моряклары большевиклар өчен бер нинди кыенлыкларның да киртә була алмауларын бөтен дөньяга күрсәттеләр. 26 ай буена Арктиканың мәкерле табигате совет кешеләрен адым саен куркыныч астында тотты. Мораль хәлнең югары булуы, дисциплиналылык, зур җаваплылыкны аңлау, бөек Ватанга, партиягә, хөкүмәткә һәм иптәш Сталинга чын күңелдән бирелгәнлек,—седовчыларга җиңеп чыгарга әнә шулар ярдәм иттеләр. (ТАСС).

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ЮККА ЧЫГАРУЫ

Финляндиядә сугыш операцияләренең икенче өч атнасы эчендә фронтта әһәмиятле үзгәрешләр булмады. Беренче өч атна эчендә Финляндия территориясендә совет гаскәрләре өчен плацдармнар төзү белән тәмам булган җидди операцияләр булган булса, икенче өч атна дәвамында эш күпчелек хәлләрдә разведка отрядларының һәм зур булмаган пехота частьләренең гадәттәге бәрелешләре белән чикләнде. Кинәт башланган көчле салкыннар фин гаскәрләренең хәлен шактый җиңеләйттеләр, ләкин, шуңа да карамастан, алар уңайлы обстановкадан җидди төстә файдалана алмадылар. Ләкин аның каравы чит ил матбугаты, бигрәк тә Франция матбугаты һәм барыннан да элек Франциянең Гавас агентлыгы, бу чор эчендә совет гаскәрләренә карата яла ягу уйдырмалары әвәләп чыгаруда зур операцияләр эшләргә өлгерделәр. Чит ил агентлыклары вәкилләренең һәрбер яла ягулы уйдырмаларын штабның көн саен юкка чыгарып торырга вакты юк. Ләкин штаб бу әфәнделәрнең яла ягу кампаниясенә вакыт-вакыт йомгак ясап тору һәм аларның чын йөзләрен ачып салу зарарлы булмас дип саный.

1. Чит ил агентлыклары Женевадан, Гельсинкидан, Ригадан алынган һич булмаган „чыганакларга“ таянып, фин гаскәрләре барлык юнәлешләрдә фронтны өзделәр, совет чиген үтеп чыктылар һәм үзләренең оперцияләрен СССР территориясендә алып баралар дип ышандыралар, — ышандырып кына калмыйлар, бәлки карлыкканчы кычкыралар. Бу төбетамыры белән ялган, шуның белән бергә балаларча, акылсыз, көлке ялган. Чынлыкта бер генә юнәлештә дә Совет чикләренә кадәр фин гаскәрләренең барып җиткәннәре юк. Алар үз алларына мондый бурычны куйдыларммы икән әле. Выборг юнәлешендә фин гаскәрләре Совет чигеннән 70 километр ераклыкта, Сердоболы юнәлешендә—80 километр, Петсамо юнәлешендә—Петсамодан көньяктарак 130 километр, Улеаборг юнәлешендә Рованиемигә таба—120 километр һәм Суомуссалмига таба — 10—15 километр ераклыкта торалар.

2. Чит ил агентлыклары, бигрәк тә Гавас агентлыгы, шул ук „чыганакларга“ таянып, Суомуссалми районындагы сугышларда Советның 44 нче дивизиясе „14 мең кешесен югалтты“ дип раслыйлар.

Бу раслау үзенең уңышсыз авторларының һич табигый булмаган фантазиясен күрсәтә. 44 нче дивизянең фронтта ни бары 10 мең чамасы кешесе булды,— ул 14 мең кешене ничек югалта алсын соң? Чынлыкта совет гаскәрләре монда 900 дән артык булмаган санда кеше югалттылар, шуның белән бергә бу югалтулар фин гаскәрләренең хәрәкәтләреннән булудан бигрәк кинәт башланган салкыннар белән аңлатыла. Ләкин чит ил гайбәтчеләре монда фин гаскәрләренең кимендә 2 мең кешеләре үтерелгәнлек һәм яраланганлык турында, шуның белән бергә совет гаскәрләре кулында „телләр“ калдырмас өчен фин шюцкорларының үзләренең яраланган гаскәрләрен ерткычларча үтерүләре турында тырышып дәшми калалар.

3. Чит ил агентлыклары, шул ук „чыганакларга“ таянып, фин гаскәрләре Мурманск тимер юлында хәбәрләшүне өзделәр һәм хәзер бу юл „бөтенләй рәттән чыгарылды“ дип раслыйлар. Бу да югарыдагы раслаулар кебек үк ялган. Бу инде югарыда әйтелгәнчә, фин гаскәрләренең бер генә пунктта да Совет чикләренә килеп җитмәгәнлекләреннән, совет чикләреннән фин гаскәрләренең уннарча километр ераклыкта, ә Мурманск тимер юлыннан йөзләрчә километр ераклыкта торуларыннан күренә. Чынлыкта Мурманск тимер юлы үзенең эшен бер генә минутка да өзмәде.

4. Шул ук чит ил агентлыклары, бер кемгә дә маглүм булмаган шул ук „чыганакларга“ таянып, „руслар Петсамоны югалттылар“ дип, „руслар немецләрне ярдәмгә чакырдылар“ дип, „Совет гаскәрләрен үзгәртеп кору өчен СССР га“ әллә 20, әллә 40, әллә инде шунда 140 „немец хәрби инструкторы килгән“ дип раслыйлар. Бу табигый булмаган гайбәтнең үзенең ялган булуы ягыннан чит ил агентлыкларындагы әфәнделәрнең барлык башка гайбәтләреннән дә узып киткәнлеген белдерергә кирәк дип саныйбыз. Петсамо 1 нче декабрьдән бирле совет гаскәрләре кулында. Совет частьләре күптән түгел генә Петсамога килгән беренче фин халык корпусы частьләре белән берлектә Петсамоны кулларында тотып кына калмыйлар, бәлки Петсамодан көньякка таба 130 километрга алгарак та киттеләр. „Совет гаскәрләрен үзгәртеп кору өчен“ имештер, СССР га килгән „немец хәрби инструкторлары“на килгәндә исә, безгә бу фантастик һәм тупас лыгырдауны кире кагуы да урынсыз. Безнеңчә Франция агентлыгындагы әфәнделәрдә бу табигый булмаган акылсыз ялганны Германия белән СССР арасындагы хәрби блок перспективасы алдында хәйваннарча курку гына тудыра алган.

Чит ил агентлыкларына аларның хуҗалары тарафыннан совет гаскәрләренә каршы пропаганда алып бару тапшырылганлыкны без аңлыйбыз. Алар үзләренең яшәүләрен аклау өчен бу „пропаганда“ ны алып баралар да һәм шуның өстенә күп санлы ялган уйдырмалар өяләр. Ләкин фактларга түгел, бәлки алдауга нигезләнгән пропаганданың бәясе нәрсә тора соң? Җәмагатьчелек фикерен системалы рәвештә алдап тору—„цивилизация“не яклаучыларның „пропагандасы“ шушыннан гыйбарәт түгелме икән? Без чит ил матбугаты вәкилләренең болай ук түбән дәрәҗәгә төшә алуларын уйламаган идек.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ҮРНӘК РӘВЕШТӘ ХӘЗЕРЛӘНИК

Алдынгы колхозларның тәҗрибәләре башка колхозларга да күчерелсен

Киров исмендәге колхозны (Әтнә районы) бик күпләр беләләр. Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенең Баш Комитеты тарафыннан беренче дәрәҗә диплом, 10 мең сум акча һәм җиңел автомобиль белән бүләкләнгән бу колхозның югары уңыш өчен көрәштәге һәм оештыру-хуҗалык эшләрендәге тәҗрибәләре күпләргә үрнәк булырлык.

Һава шартларының нинди генә булуына карамастан, колхоз ел саен игенчелектән мул уңыш ала. Җәмагать терлекчелеге елдан-ел үсә һәм аларның продукция бирүчәнлеге күтәрелә бара. Колхоз бу уңышларга, барыннан да элек, хезмәтне дөрес оештыру, машиналардан дөрес файдалану, агрозоотехника чараларын җиренә җиткереп үтәү, масса-аңлату эшләренә нык әһәмият бирү һәм эшне социалистик ярыш нигезендә оештыру нәтиҗәсендә ирешсте.

Колхозда барлык эшләргә карата норма билгеләнгән. Үтәлгән һәрбер эшнең күләмен дөрес исәпкә алып, сыйфат ягын тикшергәннән соң гына аның өчен хезмәт көне язылa. Начар сыйфатлы итеп үтәлгән эш бракка чыгарыла һәм аның өчен хезмәт көне язылмый. Эш нормалары ел саен яңадан карала һәм колхозчыларның гомуми җыелышында раслана. Правление председателе иптәш Габитов яки аның урынбасары көн саен бригадирлар белән киңәшмә үткәрә. Бу киңәшмәдә шул көндәге эшләргә йомгак ясала һәм алдагы көн өчен наряд бирелә. Бригадаларда колхозчылар белән еш кына производство киңәшмәләре үткәрелә. Анда аерым колхозчыларның эш тәҗрибәләре өйрәнелә һәм уңышлы тәҗрибәләр башкаларга күчерелә.

Һәрбер бригада һәм звено үзара ярышып эшлиләр. Шулай ук 85 колхозчы 1939 нчы елда индивидуаль йөкләмәләр алып үзара ярышып эшләгәннәр. Ярыш договорларының үтәлеше әледән-әле тикшерелеп торыла. Социалистик ярышта алдынгылыкны алучыларны бүләкләү өчен махсус фонд билгеләнеп куелган. Һәм шул фондтан үткән ел 90 стахановчы бүләкләнгән.

Шушы чараларны үткәрү колхозда хезмәтнең җитештерүчәнлеген үстерүгә нык ярдәм иткән. 11 сошниклы машина белән чәчү нормасы моннан 4—5 ел элек 4 кенә гектар булган. Хәзер бу норма 9 гектарга җиткерелгән. Ике төрәнле сабан белән сөрү нормасы 1,5 гектардан 2,5 гектарга, машина белән уру нормасы 6 гектардан 8,5 гектарга, тырмалау нормасы 3 гектардан 8,5 гектарга кадәр күтәрелгән. Колхозның стахановчылары бу соңгы нормаларны да арттырып үтиләр. Шуның белән бергә колхозчыларның хезмәт көннәре күләме дә үсә. Колхоздагы һәрбер эшкә яраклы кеше үткән ел уртача 262 хезмәт көне эшләгән. 780 колхозчыдан 227 колхозчы 3 әр йөздән артык хезмәт көне, ә стахановчылар 700 һәм аннан да артык хезмәт көне эшләгәннәр.

Агротехниканы практикада дөрес куллану колхозда югары уңыш өчен көрәштә нигез чараларның берсе булып тора. Соңгы 3 ел эчендә тирес һәм башка төрле җирле ашламалар белән 1.283 гектар җир ашланган. Бу барлык чәчү мәйданының 48 процентын тәшкил итә. Сөрү, тырмалау, культивацияләү, басуда кар тоту, орлыкларны агулау һәм яровойлаштыру, игеннәрне тукландыру кебек эшләр барсы да вактында, җиренә җиткереп башкарыла.

Колхозда культура-агарту эшләренә нык игтибар бирелә. Һәрбер бригадада стена газетасы чыгарыла. 1939 нчы елның 9 ае эчендә бригадаларда 69 данә газета чыгарылган. Бу газеталарда колхозчыларның 345 хәбәре урнаштырылган. Һәрбер бригадада агитатор эшли. Агитаторлар партия, хөкүмәт карарларын өйрәнү, халыкара хәл, дингә каршы тәрбия һ. б. турында системалы рәвештә колхозчылар белән беседалар үткәрәләр. Агрономия белемен һәм зоотехниканы өйрәнү буенча хата-лаборатория янында махсус түгәрәкләр эшли. Колхозчылар занятиеләргә кызыксынып йөриләр. Колхозда яшәп килә торган даими ясле һәм балалар бакчасыннан тыш, кыр эшләре вактында һәр ике бригада өчен бер ясле оештырылган.

Колхоз оешу-хуҗалык ягыннан ныгыган саен колхозчыларның доходлары арта, тормышлары яхшырганнан-яхшыра һәм культура дәрәҗәләре үсә бара. Колхозчылар соңгы 3 ел эчендә ел саен һәр хезмәт көненә уртача 4,6 килограмм бөртекле ашлык, 1,5 килограмм печән, 8,5 килограмм салам, 1,7 килограмм бәрәңге һәм бер килограмм яшелчә булганнар.

Киров исмендәге колхозның терлекчелек өлкәсендә һәм башка эш тармакларында да күп кенә уңышлы тәҗрибәләре бар.

Ф. Уваров.
Татнаркомзем агрономы.

Йөзпотчылар хәрәкәтенә кушылгач

Гектарыннан 100 пот иген уңышы алуга ирешү турында Калинин районы алдынгылары чакыруын Тымытык районы колхозчылары зур күтәренкелек белән каршы алдылар.

Бу хәрәкәткә районда беренче булып „Уразман“ колхозы членнары кушылдылар. Алар районның барлык колхозчыларына бу турыда хат белән мөраҗәгать иттеләр.

„Уразман“ колхозы колхозчыларының мөраҗәгате унае белән районда авыл хуҗалыгы алдынгыларының киңәшмәсе үткәрелде. Киңәшмәдә бригадирлардан, стахановчылардан, агрономнар һәм агротехниклардан, МТС һәм совхоз эшчеләреннән 200 кеше катнашты.

Киңәшмә Бөтенсоюз йөзпотчылар ярышына кушылып, 1940 нчы елда бөртекле культураларның һәр гектарыннан 100 пот, кузаклы культураларның һәр гектарыннан 70 пот, җитеннең һәр гектарыннан 36 пот һәм бәрәңгенең һәр гектарыннан 700 пот уңыш алырга йөкләмә кабул итте. Киңәшмә Мөслим районы колхозчыларын социалистик ярышка чакырды.

„Уразман“ колхозының алдынгы бригадиры иптәш Гыйззәтуллин быел бөртекле культураларның һәр гектарыннан уртача 110 пот иген уңышы алырга йөкләмә алып, Тымытык колхозы бригадиры иптәш Зариповны ярышка чакырды. Тымытык колхозының барлык бригадирлары да бу чакыруны кабул иттеләр. Хәзерге көндә „Уразман“ колхозында да һәм Тымытык колхозында да кышкы агрономия чараларын үтәү эше кызу рәвештә бара. Йөзпотчылар хәрәкәтенә кушылганнан соң районның күп кенә колхозларында язгы чәчүгә хәзерлек эше яхшырды. Мәсәлән, „Мелиорация“ колхозы авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт эшен тәмамлады. Басуга 10.100 йөк тирес чыгарды. „Якты Күл“ колхозы да ремонт эшен тәмамлады һәм басуга тирес чыгару планын 100 процент үтәде. Киров исмендәге колхоз чәчү орлыкларын 100 процент хәзерләп куйды, басуга 11.300 йөк тирес чыгарды һәм шулай ук ремонт эшен дә тәгәлләде. „Эконом“ колхозы агротехнигы, Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашкан иптәш Әхтямов сайлап алу юлы белән „Ранняя Роза“ сортлы 300 центнер бәрәңге орлыгы хәзерләде. Куйбышев һәм Киров исмендәге колхозлар үзара ярыш договоры төзеп, быел бәрәңгенең һәр гектарыннан уртача 1.000 пот һәм җитеннең һәр гектарыннан уртача 40 пот уңыш алуга ирешү турында йөкләмә алдылар.

М. Халиков.

Тракторларга ремонт ясау алдынгылары

Әлмәт МТС ы работниклары Нөркәй МТС ы коллективының чакыруын кабул итеп, тракторларга ремонт ясау планын 15 нче февральгә үтәргә йөкләмә алганнар иде. Коллектив алган йөкләмәне үтәү өчен ныклап көрәшә. 70 кеше индивидуаль социалистик ярыш договоры төзеде. 10 нчы гыйнварга тракторларга ремонт ясау планы 62 процент, авыл хуҗалыгы инвентарьларына ремонт ясау планы 75 процент үтәлде. Туманов һәм Вәлиев иптәшләрнең бригадалары тракторларга ремонт ясауны тәмамладылар. Бу бригадаларның тракторчыларыннан Архипов, Ларин, Мортазин, Гаязова, Җәмалиева һәм Шәрифуллина иптәшләр норманы көн саен 150 процент итеп үтиләр. Алар артта калып баручыларга да ярдәм итәләр. Слесарь Закиров, тимерче Карпов иптәшләр дә яхшы эшлиләр. Алар норманы көн саен 230—240 процент үтиләр.

(ТатТАСС).

Лаиш районы „Ленин юлы“ колхозында. РӘСЕМДӘ: умартачылык буенча чираттагы лекция. Колхоз умартачысы А. А. Асянина микраскоп янында.
С. Чиколкин фотосы (ТАСС фотохроникасы).

ГЕКТАРЫННАН 120 ПОТ

Әлки районы, „Комсомолец“ колхозы (председателе иптәш Минһаҗов) үткән елны бөртекле культураларның һәр гектарыннан уртача 108 пот иген уңышы алган иде. Бу колхоз йөзпотчылар хәрәкәтенә районда беренче булып кушылып, быел бөртекле культураларның һәр гектарыннан 120 пот иген уңышы алуга ирешүне йөкләмә итеп алды.

Н. Гобәй.

ВУЗЛАРДА ЭКЗАМЕННАР

ЯГЕЗ, СӨЙЛӘШЕП КАРЫЙК ӘЛЕ!

Шулай итеп, без Казан университетының 43 нче номерлы аудитуриясендә утырабыз. Амфитеатр сымак итеп, берсен икенчесеннән биегерәк күтәртеп ясалган утыргычларда яшерәк кенә өч кыз, ике егет утыралар. Аларның йөзләрендә эшчән тынычлык һәм үз-үзләренә ышану билгеләре күренә. Аудиториянең зур-зур тәрәзәләреннән кояшның иртәнге шаян нурлары коелып, биредә утыручыларның битләрен яктыртта һәм аларның күзләрендә яна торган яшлек очкыннарын тагын да ачыгырак итеп күрсәтә башлый. Биредә бер нәрсә дә артык түгел, барсы да үз урнында: фәнгә гомерләрен биреп киткән олы кешеләрнең маһабәт портретлары, чал чәчле картлык һәм янып торган битле яшлек. Тагын бик кирәкле бер нәрсә бар биредә, ул—тынлык. Тирән тынлыкны экзаменатор иптәш Власовның иптәшләрчә җылы, ләкин шуның белән бергә ялагайлануга юл куймый торган кырку тавышы боза:

— Ягез әле, иптәшләр, сезнең белән сөйләшеп карыйк әле,—дип сүзгә керешә ул.

Экзаменаторның каршында биология факультетының V нче курс студенткасы иптәш Ивановская утыра. Ул башка фәннәрдән „яхшы“ һәм „отлично“ билгеләренә экзамен биргән, ул бүген партия тарихы буенча экзамен бирә. Тема: Антантаның советка каршы походлары, партиянең шул вакытта алып барган оештыручылык роле, хиянәтчеләргә каршы көрәше һәм коммунистлар партиясенең дөрес җитәкчелеге нәтиҗәсендә советлар республикасының җиңеп чыгуы.

Иптәш Ивановская шушы катлаулы һәм җаваплы теманы ашыкмыйча, логикалы рәвештә ачык һәм аңлаешлы итеп сөйләп бирә. Ул гомуми фразаларны җибәрми, үз башыннан „яңа хикмәтләр“ дә уйлап чыгармый, ә тарихның шул вакыттагы бер өзеген нак тарихтагыча итеп, бәйләнешле һәм ышандыра торган итеп сөйләп чыга. Бу инде гади укучы сөйләве генә түгел, бу—логикалы итеп уйлый белә торган һәм һәр яклап белемле булган кешенең сөйләве. Бу инде—өлгергән речь, фәнчә җыйнак һәм тыгыз речь. Иптәш Ивановская икенче, өченче темалар буенча да ачык һәм күңелне чын магнәсе белән канәгатьләндерә торган итеп сөйләп бирә. Аннан соң бик кыска гына бер вакыт эчендә аудитория тынып кала, экзаменатор „үзенең җимеше“ белән үзе мавыккан төсле итеп рәхәтләнеп бер карап куя, йөзләргә үзара ихтирам билгеләре чыгалар һәм әнә шуларның барсыннан да соң экзаменатор экзамен тотучы иптәш Ивановскаядан аның сынау кнәгәсен сорап ала. Берничә „отлично“ һәм берничә „яхшы“ билгеләре янына тагын бер „отлично“ билгесе өстәлә. Ивановская шатланып, аудиториядән чыгып китә. Ишек төбендә аны иптәшләре очраталар, аның шатлыгын уртаклашалар, сорашалар, үзара пышылдашалар. Фәннең ишеге төбендә мәңгелек яшлек басып тора, фән картаюны белми, чөнки Ивановская төсле яшьләр аңа картаерга ирек бирмиләр, алар фәнгә үзләренең яшлек җылылыкларын кушып, аны күтәреп, мәңгелеккә алып баралар.

Экзаменаторның каршына икенче бер яшь кеше, куе кара чәчле, киң маңгайлы, йомшак яшькелт күзле, сөйкемле бер яшь кеше—иптәш Юшков килеп утыра. Иптәш Юшков—заочник. Ул Кайбыч урта мәктәбендә математика фәне укыта икән. Капризлы математикадан алып диңгез төсле тирән тарих фәненә чаклы булган ара—алай якын түгел. Болар арасына тагын физика, химия, тел, әдәбият фәннәре керәләр, болар арасына тагын бик күп йокысыз төннәр керәләр. Ләкин иптәш Юшков боларның берсеннән дә курыкмаган, ул ерак һәм читен араны, безнең чорның яшь кешесенә хас рәвештә, башын югары тотып үтә алган. Ул бүген партия тарихыннан „отлично“ билгесенә экзамен тапшырды.

Иптәш Юшков—безнең чорның яшь кешесе ул. Аны көрәш һәм эш романтикасы кызыктыра. Ул „ирешелгән биеклек“ белән канәгатьләнеп калмыйча, бер туктаусыз эшли, көрәшә, яңа биеклекләргә омтыла.

Ә бит алар—тыңгысыз җанлы ул яшь кешеләр — бик күпләр. Бүген, университет коридорларында, култык асларына китапларын кыстырып, экзаменатор янына керергә чират көтеп торучы ул яшьләр турында чынлап та горурланып сөйләргә була. Безнең яшьләребез хәзер инде колачлап йөзәргә өйрәнеп киләләр. Алар фәннең бер тармагы белән генә чикләнмиләр, тагын да күбрәк белүгә омтылалар.

Казан университетында булу, экзамен тотучы яшьләр белән бик аз гына вакыт очрашу, аларның сынау кнәгәләренә күз ташлау моны тагын бер катрасланый. Партия тарихыннан экзамен тотучы 80 ләп кешедән (IV—V нче курс студентлары) 52 се „отлично“, 27 се „яхшы“ билгеләре алып, бары тик бер кеше генә „канәгатьләнерлек“ билгесе белән калган. Болар махсус тарих факультеты студентлары түгел, болар—биологлар, химиклар, физиклар. Шуның белән бергә болар биологиянең, химиянең, физиканың тарихтан башка була алмаганлыгын чын күңелдән төшенгән кешеләр.

Алар, китапларын күкрәкләренә кысып, университет коридорларыннан шаулашып узалар. Фәннәрне яңача штурмлаучы бу яшь кешеләрнең һәрберсенең аларның һәрбер „отлично“ билгесе саен кулларын кысасы килә!

Ф. Хөсни.

БАЛАЛАРНЫ КОММУНИСТИК РУХТА ТӘРБИЯЛӘҮНЕ КӨЧӘЙТИК

Ленин—Сталин партиясенең тарихи XVIII нче съезды Сталинчыл өченче бишьеллыкта хезмәт ияләрен коммунистик рухта тәрбияләү бурычына гаять зур әһәмият бирде. Хезмәт ияләрен югары культуралы итү, аларның белемнәрен күтәрү, аңнарында бу көнгә кадәр яшәп килгән капитализм калдыкларын, иске гореф-гадәтләрне бетерү, хезмәт ияләрен бөек Ватаныбызга, большевиклар партиясенә чын күңелдән бирелгәнлек рухында тәрбияләү—болар гаять әһәмиятле һәм һич кичектерелмәслек бурычлар булып торалар.

Безнең Ватаныбыз хезмәт ияләренең культураларын күтәрү эшендә гаять зур уңышларга ирешсте. Иптәш Сталин бу турыда бик ачык итеп болай диде:

„Халыкның культура үсеше ягыннан караганда отчет чоры чын-чыннан культура революциясе чоры булды. СССР милләтләре телләрендә гомуми мәҗбүри башлангыч белем алуны тормышка үткәрү, мәктәпләр саны һәм барлык баскыч мәктәпләрдә укучылар саны арту, югары мәктәпләр чыгара торган белгечләр саны арту, яңа, совет интеллигенциясен булдыру һәм ныгыту,—халыкның культура күтәрелешенең гомуми картинасы әнә шундый“.

Сталинчыл өченче бишьеллык планда культура төзелешенең зур программасы билгеләнде: шәһәрдә гомуми урта белем бирүне тормышка ашыру, авылда һәм барлык милли республикаларда җиде еллык гомуми белем бирүне тәгәлләү бурычы куелды.

Хезмәт ияләрен, яшь үсмерне бөек большевиклар партиясенә чын күңелдән бирелгәнлек рухында тәрбияләү, аларда социалистик хезмәткә аңлы һәм намуслы караш тәрбияләү, большевистик сыйфатлар тәрбияләү эше, беренче чиратта, совет мәктәбендә башланырга тиеш.

Безнең республикабызда күп кенә мәктәпләр һәм аларның җитәкчеләре үз алларында торган политик бурычны дөрес аңлыйлар һәм яшь үсмерне коммунистик рухта тәрбияләү эшен тормышка үткәрү өчен чын-чыннан большевикларча көрәшәләр. Дөрес, балаларны тәрбияләү—ул, мәктәп эше генә түгел, бәлки бөтен җәмагатьчелек эше.

Дөбъяз районының К. Рәс авылындагы тулы булмаган урта мәктәбе быелгы уку елында зур уңышларга ирешсте. Биредә мәктәп дирекциясенә комсомол оешмасы зур булышлык күрсәтә. Комсомол оешмасы отлично уку өчен социалистик ярыш оештырып, укучы балалар арасында дисциплинаны ныгытуда һәм укуда яхшы нәтиҗәләргә ирешүдә дирекциягә практик ярдәм оештырды. 7 нче класста укучы комсомолец Шамиль Закировның берничә начар билгесе була, ул дисциплинага буйсынмый. Комсомол оешмасы Закировның мәсьәләсен җыелышта тыңлый һәм конкрет чаралар билгели. Комсомол оешмасының секретаре иптәш Шәйхетдинов аның укуы белән танышып бара, укытучылар белән сөйләшә, аңа отлично укучыларны беркетә. Һәм озак та үтми, Закиров II нче чирекне „отлично“ һәм „яхшы“ билгеләренә тәмам итә. Тикшерү нәтиҗәсендә, Закировның фото белән нык кызыксынуы беленә һәм мәктәп моны искә алып, мәктәптә фото түгәрәк оештыра һәм Закировны аның җитәкчесе итеп билгели.

Шул ук мәктәптә укытучы иптәш Фазылҗанов IV нче класста укучы Сибгатуллинның начар укый башлавына игтибар биреп, аның белән якыннан шөгыльләнә башлый. Сибгатуллинга аның үги анасы күп эш тапшыра. Бала дәрескә хәзерләнә алмый. Иптәш Фазылҗанов квартирага бара, аның анасы белән сөйләшә һәм тиешле ярдәмне күрсәтә. Сибгатуллин II нче чиректә 91 процент өлгереш алуга ирешә.

Мондый, үз эшенә намус белән караучы, үз алдына куелган бурычны тулысынча үтәү өчен чын-чыннан большевикларча көрәшүче иптәшләр бездә күп. Алар аерым балаларның укулары белән тирәнтен кызыксыну белән бергә, үз классларында 100 процент өлгереш өчен сугышчан рәвештә көрәшәләр. Быелгы уку елының беренче яртысын зур уңышлар белән тәмамлаган мәктәпләр моның ачык күрсәткече булып торалар.

Шулай да, республикабызның күп кенә мәктәпләрендә балаларны тәрбияләү эше тиешле югарылыкка куелмаган әле. Кайбер мәктәпләрнең җитәкче работниклары бу мәсьәләдә җавапсызлык күрсәтәләр.

Биектау районындагы Ямашурма авылының тулы булмаган урта мәктәбендә укыту-тәрбия эше аеруча начар оештырылган. Бу мәктәп беренче чирекне бары 45 процент өлгереш белән тәмам итте. Югары классларда өлгереш тагын да начаррак иде. 7 класста өлгереш 6 процент булды. Ләкин бу саннар мәктәп директоры иптәш Нәбиуллинны да һәм шулай ук укытучылар коллективын да борчымаган, күрәсең. Алар II нче чирекне дә шундый ук саннар белән тәмам иттеләр.

Казан шәһәрендә дә мондый фактларны еш очратырга мөмкин. Мәсәлән, 5 нче урта мәктәп (Молотов районы) укучыларының 39,3 проценты беренче чирекне начар билгеләре белән тәмам итте. Начар билгесе алучылар арасында комсомолецлар, пионер отряды вожатыйлары да бар. Комсомолец вожатый Мартыновның—3, Качморжинның—4, Росмоткинның—2 начар билгеләре бар. Укучылар арасында эчүчелек белән шөгыльләнүче һәм хулиганлык итүче укучылар да юк түгел. Ләкин мондый фактлардан дирекция һәм комсомол оешмасы үзләренә тиешле нәтиҗә ясамаганнар. Шуның өчен дә мәктәптәге 1.300 укучыдан бары тик бер отличник булуы гаҗәп түгел.

Мондый фактларның бу көнгә кадәр яшәп килүен бары тик халык мәгарифе органнары работникларының, комсомол оешмаларының балаларны тәрбияләү эшенә ныклы игтибар бирмәүләреннән килеп чыккан дип әйтергә кирәк. Мәгариф органнары яхшы үрнәкләр күрсәтүче укытучыларның эш тәҗрибәләрен уртаклашу, кадрларны үстерү һәм аларны тәрбияләү эшенә чын-чынлап керешкәннәре юк әле. Яшь укытучылар арасында политик - тәрбия эшләре һич тә канәгатьләнерлек түгел. Тәҗрибәләрне уртаклашу буенча киңәшмәләр системалы рәвештә алып барылмый. Укытучылар өстеннән контрольлек эше җитәрлек түгел. Моны раслау өчен Ютазы районындагы Урыс Суы тулы булмаган урта мәктәп укытучыларыннан Әмирханова, Баширова, Хәсәнова, Гатауллина иптәшләрне күрсәтергә мөмкин. Бу иптәшләр үз белемнәрен, квалификацияләрен күтәрү өстендә эшләмиләр. Хәтта политик белемнәрен күтәрү өстендә дә эшләмиләр. Алар, үзләренең әйтүләренә караганда, „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“ның беренче бүлеген генә өйрәнәләр әле.

Бигәш авылындагы (Әлмәт районы) тулы булмаган урта мәктәп укытучыларыннан Мөхәмәдеев, Рөстәмев иптәшләрнең гомуми белемнәре җитәрлек түгел. Шуңа карамастан, алар читтән торып укымыйлар, ВКП(б) тарихын да өйрәнмиләр.

Ленин—Сталин партиясе балаларны һәм яшь үсмерне коммунистик рухта тәрбияләү буенча комсомол оешмалары алдына гаять зур бурычлар куйды. ВЛКСМ Үзәк Комитетының үткән елның декабрь аенда булып үткән X нчы пленумы үзенең бөтен эшен шушы мәсьәләгә багышлады. ВЛКСМ Үзәк Комитеты секретаре иптәш Михайлов, пленумда ясаган докладында, комсомол оешмаларының мәктәптәге эшләрен тулы ачыклыгы белән тагын бер тапкыр күрсәтте.

Комсомол оешмаларының мәктәптәге эшләре, беренче чиратта, укытучыларның авторитетын күтәрүгә, балаларны тәрбияләүдә һәм укытуда аңа барлык чаралар белән булышлык итүгә, мәктәптә тәртипне һәм дисциплинаны ныгытуга юнәлдерелгән булырга тиеш. Комсомол һәм пионер оешмаларының эшләре нак менә шушы нигездә яңартып корылырга тиеш.

Ләкин бездә комсомол оешмалары мәктәп мәсьәләләре белән тирәнтен шөгыльләнмиләр, укытучылар кадрларын политик яктан тәрбияләү мәсьәләсе белән җитәрлек кызыксынмыйлар әле. Республикада 350 өлкән вожатый булырга тиеш иде. Бу көнгә кадәр бары тик 203 вожатый расланган 154 отрядта вожатыйлар бөтенләй юк. Укытучылар исәбенә комсомол сафларының бик аз үсүен, Казан шәһәрендә үткән елның III нче кварталында комсомол сафларына алынган 1.071 укучы яшьләрдән укытучыларның бары тик 8 кеше булуын һәм Биектау районында 1939 нчы елда кабул ителүчеләр арасында укытучылардан бер генә кеше булуын нәрсә белән аңлатырга соң?

Совет хөкүмәте һәм бөек большевиклар партиясе хезмәт ияләрен, яшь үсмерне коммунистик рухта тәрбияләү эшенә гаять зур әһәмият бирәләр һәм моның өчен тулы шартларны булдыралар. Ленин—Сталин партиясенең һәм хезмәт ияләренең бөек юлбашчысы иптәш Сталинның кайгыртучанлык күрсәтүләре белән чолганып алынган совет укытучысы өчен, совет балаларын бөек партиябезгә, Ватаныбызга чын күңелдән бирелгәнлек рухында тәрбияләү эшеннән дә бөегрәк, почетлырак эш юк. Укытучылар коллективы, комсомол һәм пионер оешмалары белән берлектә, үз алларына куелган бу мөһим политик бурычны, большевиклар партиясе җитәкчелегендә уңышлы үтәр. Моның өчен бездә бөтен мөмкинлекләр бар.

Рим Баһау.

КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫННАН

Хезмәт ияләре депутатларының Казан Шәһәр Советы башкарма комитеты үзенең 14 нче гыйнвардагы утырышында шәһәрдә икмәк белән сәүдә итү турындагы мәсьәләне карады.

Чиратларны бетерү, спекуляциягә каршы көрәшү һәм икмәк белән сәүдә итүне нормаль хәлгә кую теләге белән, СССР Совнаркомының 1937 нче ел 25 нче августтагы карарына таянып, хезмәт ияләре депутатларының Казан Шәһәр Советы башкарма комитеты Горхлебторг директоры иптәш Гудошниковны, Киров районы пищеторг директоры иптәш Сәгдеттиневне һәм шәһәр сәүдә бүлеге мөдире иптәш Сотниковны бер кулга 2 килограмнан артык икмәк сатмау өчен контроль булдырырга мәҗбүр итте.

Милиция идарәсе начальнигы иптәш Соколовка һәм СССР наркомторгының дәүләт сәүдә инспекциясе вәкиле иптәш Кузюмовка, куелган нормадан артык икмәк сатулар булган хәлләрдә һәм шулай ук спекуляция теләге белән яки икмәкне терлекләргә ашату теләге белән алу булган хәлләрдә гаепле кешеләрне җинаят тәртибендә җавапка тартырга такдим итте.

Шәһәр Советы башкарма комитеты хезмәт ияләре депутатларының район советы башкарма комитетларын икмәк белән сәүдә итү кагыйдәләрен саклауга системалы контроль ясау эшенә депутатларны һәм совет активын тартырга мәҗбүр итте.

Икмәкне билгеләнгән нормадан артык сатып алуларны булдырмаска, билгеләнгән нормадан артык сатып алынган икмәкне кире кайтарыл алырга. Бу эштә тулы булышлык күрсәтү милиция идарәсе начальнигы иптәш Соколовка такдим ителде.

Горхлебторг директоры иптәш Гудошниковка һәм Киров райпищеторгы директоры иптәш Сәгдеттиновка кире алынган икмәкне кабул итү эшен билгеләнгән махсус сәүдә точкаларында оештырырга такдим итте.

Казан Шәһәр Советы башкарма комитеты.

МТС ларда тракторларга ремонт ясауның барышы турында Татарстан Җир Эшләре Халык Комиссариаты сводкасы

1940 нчы елның 10 нчы гыйнварына
(Көзге-кышкы ремонт планына карата процентларда)

МТС лар исме	Үтәлеш	МТС лар исме	Үтәлеш
Нөркәй	100,0	Калинин	29,6
Тымытык	100,0	Ишеево	29,4
Теләче	102,4	Иске Тимошкино	29,3
Кама Тамагы	85,7	Кызыл Юл	28,8
Черемуховский	78,6	Биектау	28,2
Зур Полянә	76,3	Акташ	27,9
Актаныш	76,1	Тат. Ялтан	27,8
Чалпы	71,4	Морты	27,7
Т. Тамак	68,2	Буа	25,6
Әлмәт	66,7	Буденный	25,5
Маткавыш	62,6	Чокалы	25,5
Аксубай	62,4	Арча	25,0
Тирсә	62,2	Чыбыклы	24,3
Азин	61,3	Норлат	23,9
Яниль	61,2	Зур Кләре	22,9
Мамадыш	50,0	Иске Чишмә	22,7
Чүпрәле	48,8	Кошкинский	22,5
Этнә	48,0	Поповка	22,4
Чишмә	46,7	Баулы	21,9
Тархан	46,5	Константиновка	21,9
Кызыл Чапчак	46,0	Кызыл Йолдыз	21,8
Столбище	45,5	Питрәч	21,4
Тәкәнеш	45,2	Балтач	20,8
Дәүләки	45,0	Трехозерский	20,0
Алга	44,4	Кузайкино	19,2
Юртыш	44,0	Юдино	19,1
Чаллы	43,7	Бөгелмә	18,6
Саба	43,2	Дөбъяз	18,5
Сарман	41,4	Ромадан	18,2
Каргалы	41,1	Чиябаш	18,0
Октябрь	41,1	Салман	17,6
Чистай	40,0	Беренче Май	17,1
Биләр	39,6	Зирекле	17,1
Кадрәк	39,0	Карамалы	16,3
Куйбышев	38,0	Зөй	15,7
Мәлки	37,5	Шөгер	15,7
Бондюг	37,2	Үзәк	15,4
Кичү	37,0	Мөслим	14,3
Кузнечиха	37,0	Чүрибураш	14,0
Тәтеш	36,5	Яңа Чишмә	13,3
Кәкре Елга	36,4	Кукмара	12,5
Ютазы	36,4	Тельман	12,0
Әхмәмәт	35,4	Рождественский	11,5
Алабуга	35,7	Тат. Ходяш	10,6
Макыл	35,3	Әлки	10,2
Балык Бистәсе	35,1	Мөрәле	10,2
Соколка	33,3	Димитров	9,1
Иске Писмән	33,3	Барлыгы	34,7
Мөслим (Чистай)	33,3	1940 нчы елның 5 нче гыйнварына	30,0
Әлши	33,3	1939 нчы елның 10 нчы гыйнварына	27,0
Мәйдан	32,3		
Алексеевский	31,8		
Исәнбай	31,6		
Базарлы Матак	31,5		
Минзәлә	30,9		

Искәрмә: Зөя МТС ында ремонтланган тракторлар юк.



РӘСЕМДӘ: экзаменнарын срогыннан алда „отлично" һәм „яхшы" билгесенә тапшырган һәм кышкы каникулга өйләренә кайтучы медицина институты студентларыннан бер группа. Сулдан— Надя Сорокина, Шура Карнаухова, Миша Панков, Маруся Дергилева һәм Петя Ванюков. Б. Невзоров фотосы.

Казан Дәүләт университеты студентларының кышкы каникулы

Казан Дәүләт университетының студентлары үзләренең кышкы каникулларын күңелле һәм культуралы итеп үткәрергә хәзерләнәләр. 24 нче гыйнварда университетта беренче семестрны тәмамлауга багышланган кичә булачак. Кичәдә студентлардан җырчылар, биючеләр, музыкантлар, декламаторлар, физкультурниклар чыгыш ясаячаклар.

Чаңгы походы үткәрү өчен кызыклы маршрутлар билгеләнде. 22 нче гыйнварда Ленинның беренче тапкыр сөргенгә җибәрелгән урны булган Кокушкино—хәзерге Ленино авылына чаңгыларда массовый экскурсия үткәреләчәк. Студентлар Займищегә, Обсерваториягә, Зөядәге туристлар лагерына һәм башка урыннарга чаңгы белән барачаклар.

Каникул вактында Саратов университеты хоккейчылары белән очрашу, шахмат турниры үткәрү, Казан музейләренә һәм предприятиеләренә экскурсияләр ясау күздә тотыла. Студентлардан 95 кеше ял йортларына җибәреләчәк, 50 кеше Москвага һәм Ленинградка барачаклар. (ТатТАСС)

Татарстан АССР ның 20 еллыгына хәзерлек

Татарстан АССР Осоавиахимының Үзәк Советы президиумы Осоавиахим оешмаларының Татарстанның 20 еллык юбилеенә хәзерләнү планын раслады.

Республикабызның данлыклы юбилеенә хәзерләнүдә төп бурыч итеп һәрбер колхозда, учреждениедә һәм предприятиедә Осоавиахимның башлангыч оешмаларын төзү, значкистлар хәзерләү буенча еллык контроль заданиене юбилей көненә 60 процентка үтәү куела.

Кавалерия мәктәбе Татарстан районнарында атлы-чаңгы ярышлары һәм ат ярышлары оештыра. Дингез клубы май аенда Казан—Чистай маршруты белән шлюпкаларда поход үткәрә. Чистай, Алабуга, Тәтеш һәм Бөгелмә районнарында химиядән саклану ярышлары үткәрелә.

СУГЫШЧЫЛАРГА БҮЛӘКЛӘР

Татарстан геология-разведка тресты работниклары 13 нче гыйнварда үзләренең җыелышларында Ленинград Хәрби Округының батыр сугышчыларына бүләкләр җибәрү турында карар кабул иттеләр. Җылы әйберләр һәм башка бүләкләр сатып алу өчен шул ук көнне 3 сәгать эчендә 1.870 сум акча җыелды. Бүләкләр алу өчен акча керү дәвам итә.

Ленин һәм 9 нчы гыйнвар турында күргәзмә

Татпромсовет китапханәсе В. И. Ленинга һәм 1905 нче елгы революциягә каратылган әдәбияттан күргәзмә төзеде. Күргәзмә фото - монтаж белән бизәлде.

Татпромсовет системасындагы артельләрдә Владимир Ильич Ленинның тормышын һәм революцион эшен өйрәнү буенча художество әдәбияты укулар оештырылды. Шулай ук 9 нчы гыйнвар турында да беседалар алып барыла.

А. Усманов.

Физкультура кичәсе

Зеленодольск шәһәренең „Париж коммунасы" клубында физкультурникларның хезмәт иясе яшьләр катнашы белән физкультура кичәсе үткәрелде. 800 дән артык физкультурник һәм яшьләр үзләренең бу җыелышларында ГТО ның яңа комплексын тикшерделәр.

Кичәдә ГТО ның яңа комплексы турында спорт һәм физкультура эшләре буенча республика комитеты вәкиле иптәш Федотов доклад ясады. Доклад буенча фикер алышулардан „Зенит", „Судостроитель", „Красная Звезда" спорт җәмгыятьләренең вәкилләре сөйләделәр һәм алар яңа комплекс буенча значкистлар хәзерләп чыгару турында үз өсләренә конкрет йөкләмәләр алдылар. Җыелыштан соң 30 кешелек физкультурниклар бригадасының окробатика һәм гимнастика чыгышлары булды. Бригада шулай ук гимнастика буенча ГТО комплексыннан II—III разрядларны күргәзмә номерларда башкарды.

ГТО ның яңа комплексын пропагандалау теләге белән үткәрелгән бу кичә бик җанлы үтте. *К. Прозоров.*

Чит илләрдә

ЕВРОПА СУГЫШЫ

ПАРИЖ, 13 гыйнвар. (ТАСС). Кичә көндез фронтта разведка частьләренең бары тик җирле характердагы хәрәкәте генә күренде, дип хәбәр итәләр. Төнлә әһәмиятле бер нәрсә дә булмаган.

БЕРЛИН, 13 гыйнвар. (ТАСС). Германия армиясенең верховный командованиесе, кичә дошман самолетларының аерым төнге очышлары булганлыгын һәм ул самолетларның тагын Голландия нейтралитетын бозып хәрәкәт иткәнлекләрен хәбәр итә. Германия территориясе өстендә дошманның тик бер генә самолеты күренгән. Кыска гына вакытка сузылган сугыштан соң самолет Германия истребительләре тарафыннан бәреп төшерелгән һәм Франция территориясенә төшкән. Бер бухтада Англиянең 8 бомбардировщигы Германия эсминецларын бомбага тотканнар. Бомбардировщикларның бары тик икесе үзләренең бомбаларын ташлый алганнар. Ләкин бу бомбалар тиешле урыннарына төшмәгәннәр. Бер бомбардировщик бәреп төшерелгән, икенчесе зарарланган, ә калган 6 сы Германия эсминецларыннан ачылган көчле зенит уты астында кирегә борылганнар.

„Демократик" Франциянең „гадел хөкеме"

Декабрь ахрында Булонь Сюр-Мер шәһәрендә тарих һәм география укытучысы—57 яшьлек Луиза Пюссе дигән хатынга суд булды. Луиза Пюссе „турыдан-туры яки читләтә коммунистик лозунглар тарату теләге белән активлык күрсәтүдә" гаепләнде. Карт укытучының җинаяте, аның СССР га карата мәхәббәт белән фикер белдерүеннән гыйбарәт.

„Пти паризьен" газетасының язуына караганда, 40 тан артык шаһит—мәктәпнең укучылары һәм укытучылары Луиза Пюссене яклап чыкканнар. Судта булган күп сандагы халык үзенең Луиза Пюссе белән бердәмлеген көчле рәвештә күрсәткән һәм аның „гаеплелеген" исбат итәргә маташучы суд председателенең үз-үзен тотуына карата ачу белдергән. Моның белән санашмаучы судья бөтен халыкны утырыш залыннан чыгару турында приказ биргән.

Франциянең икенче газетасы „Матэн"ның хәбәр итүенә караганда, укытучы Луиза Пюссе, „Дәресләр вактында СССР га карата соклану белдергәнлеге" өчен, Булонь суды тарафыннан шарт белән дүрт айга төрмәгә хөкем ителгән.

13 гыйнвар. (ТАСС).

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

КӨНЬЯК КЫТАЙДА

Гуанси провинциясендә Люцзян елгасыннан көньякта операцияләр алып баручы кытай частьләре 10 нчы гыйнварда Уцзун авылы тирәсендә (Наньниннан көньякта) японнарның позицияләренә атака ясадылар. Кытай частьләре, берничә тапкыр каты атака ясаганнан соң, японнарның оборона линияләрен өзделәр һәм авылны алдылар. Сугышта берничә йөз япон солдаты һәм офицеры үтерелде һәм яраланды. Наньнин—Циньчжоу шоссесендә булган соңгы сугышларда кытайлар тагын ике пунктны алдылар. Японнарның контратакалары кире кайтарылды.

Гуандун провинциясендә, Кантоннан төньякка таба 60 километрда, кытайлар японнарның 3.000 кешелек отрядын чолгап алдылар. Кытайларның ике колоннасы бу отрядны чолгап алудан элек операция алып бардылар. Кытайлар, 10 нчы гыйнварда Бэйцзян елгасы аркылы чыгып, ике колонна белән көньякка таба һөҗүм башладылар. Бу колонналарның берсе Кантон—Ханькоу тимер юлы буйлап, икенчесе тимер юлдан көнбатыштарак булган шоссе буйлап хәрәкәт итә. Колонналар үзләренең юнәлешләрендә шактый алга киттеләр һәм үзара элемтә урнаштырдылар. Шулай итеп япон отрядларының бу районнан чигенү юллары киселгән хәлдә булып калды.

ҮЗӘК КЫТАЙДА

Сентрал Ньюс агентлыгы тарафыннан бирелгән мәгълүматларга караганда, Люаньчжоу (Аньхуэй провинциясенең көнбатыш өлешендә) районында 4 нче гыйнварда булган сугышларда японнар арасында „атакалар короле" сыйфатында атаклы булган япон полковнигы Миури үтерелгән. Миури күптән түгел генә Лучжоуда япон гарнизоны начальнигы постына билгеләнгән иде.

Цзянси провинциясенең төньяк өлешендә кытай гаскәрләре 9 нчы гыйнварда Махулинны (Цзюцзяннан көньякта) алдылар һәм Цзюцзянга һөҗүмне дәвам иттерәләр.

Хубэй провинциясендә кытай частьләре 10 нчы гыйнварда Мапинцзянны (Суйчжоудан көньяк-көнчыгышта) әйләндереп алдылар. Шул ук көнне кытайлар Вэйцзяцзянны (Мапинцзяннан көньяк-көнбатышта) японнардан тазарттылар. Кытай гаскәрләре шушы пунктларны алып, Иншань—Суйчжоу—Аньлу линиясендә японнарның юлларын өзделәр. 10 нчы гыйнварда кытай гаскәрләренең удар колоннасы японнарның Иншаньнан көньяк-көнчыгышта урнашкан мөһим базаларына көтелмәгәндә атака ясады.

Хенань (Синьяннан төньяк-көнбатышта) провинциясенең көньяк өлешендә японнарның катнаш частьләре—пехотасы, кавалериясе, артиллериясе һәм бронечастьләре—7 нче гыйнварда кытайларның позицияләренә энергияле һөҗүм башладылар. 9 нчы гыйнварда японнарның барлык атакалары кире кайтарылды. Японнар Синьяннан көнбатышка таба 20 километрда урнашкан пунктка ашыгыч рәвештә чигенергә керештеләр.

„Дамейбао" газетасы тарафыннан бирелгән мәгълүматларга караганда, 10 нчы гыйнварда партизаннар Ханькоу тирәсендә, Янцзы елгасында, японнарның „Цзунманмару" дигән пароходларын батырдылар. Пароходта күп санда сугыш кирәк-яраклары урнашкан булган. Команданың 20 кешесе һәлак булган.

Төньяк Кытай фронтларындагы хәл турында мәгълүматлар юк.

Транспорт командирлары һәм политработниклары товар поездларында

Казан тимер юлында гыйнвар аеннан башлап транспорт командирлары һәм политработниклары товар поездлары белән йөрүне куллана башладылар.

Товар поездларын озату өчен юл бүлекләренең җаваплы работникларыннан 162 кеше, политбүлекләр һәм партия оешмалары работникларыннан 66 кеше билгеләнде.

Беренче тәҗрибәләр болай эшләүнең гаят файдалы икәнлеген күрсәттеләр. Командирлар яки политработниклар тарафыннан озатыла торган поездлар, кагыйдә буларак, билгеләнгән графикадан тизрәк йөриләр.

(ТатТАСС).

ЯШ МАТЕМАТИК

1938 нче елны Москва Дәүләт университетының механика-математика факультеты деканатына Игорь Шафаревич дигән яшь үсмер килә. Ул үзенең урта мәктәпне бетергәнлеген һәм Университетка керергә теләгәнлеген белдерә. Ул вакытта әле Игорьга 15 яшь тә тулмаган була һәм аны кабул итүдән баш тарталар. Ләкин ул үзенең теләген куәтләүдә дәвам итә. Шафаревич 2 ел буе университетның бишьеллык курсын үзлегеннән өйрәнә, 30 экзамен бирә. Бу экзаменнарның 26 сын ул „отлично" билгесенә һәм 4 сен „яхшы" билгесенә тапшыра. Шушы көннәрдә ул механика-математика факультетының 5 нче курсына кабул ителә.

Шафаревич математиканы, бигрәк тә югары алгебраны һәм саннар теориясен ярата. Ул шушы дисциплиналар буенча специальләшә. Аның математика буенча белемнәре инде университет курсыннан да артып китәләр.

Шафаревич фәнни түгәрәкләр һәм семинарлар эшендә актив катнаша. Москва Дәүләт университетының профессорлары аның сәләтлелегенә югары бәя бирәләр. Яшь математик хәзер дәүләт экзаменнары тапшыруга хәзерләнә. (ТАСС).

МОСКВА МЕДИЦИНА ИНСТИТУТЫНЫҢ 175 ЕЛЛЫГЫ

СССР Наркомздравында Москваның 1 нче Дәүләт Медицина институтының 175 еллыгын бәйрәм итүне үткәрү буенча юбилей комитетының утырышы булды.

Комитет институтның тарихына һәм аның эшлеклеләренә багышланган фәнни хезмәтләр басып чыгару планын раслады.

Шушы елның май башында юбилей тантаналары үткәреләчәк. Шул вакытта Москвада „Иң карт медицина институтының 175 еллыгы" дигән темага зур күргәзмә ачылачак.

БЕЛДЕРҮ

Шушы елның 16 нчы гыйнварында 18 сәгатьтә ВКП(б) Шәһәр Комитетының утырышлар залында, фабрика-завод газеталары редакторлары, редактор урынбасарлары, әдәби сотрудниклар өчен семинар була. Тема: „Большевистик матбугат турында Ленин һәм Сталин". Килү мәҗбүри.

ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитеты.

Шушы елның 15 нче гыйнварында 18 сәгатьтә Дәүләт университетының актовый залында, докладчылар өчен инструктив җыелыш була. Тема: „ИПТӘШ СТАЛИН ҖИТӘКЧЕЛЕГЕНДӘ ЛЕНИН ЮЛЫ БЕЛӘН ЛЕНИННӘН БАШКА 16 ЕЛ". Пропусклар ВКП(б) райкомнарында бирелә.

ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитеты.

Җаваплы редактор Һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

С. М. КИРОВ ИСМЕНДӘГЕ
КАЗАН ХИМИКО-ТЕХНОЛОГИЯ ИНСТИТУТЫ
институтка хәзерлек буенча 6 айлык курсларга өстәмә рәвештә
УКУЧЫЛАР АЛА
Курсларга тегәлләнгән урта белемле (10 еллык мәктәп, техникум, рабфак тәгәлләгән) кешеләр алыналар.
Хәзерлек курсларында укулар производстводан аерылмыйча алып барыла.
Гаризалар, ВУЗ ларга керү өчен сорала торган документлар белән, шушы ел 22 нче гыйнварга кадәр, институтның кадрлар бүлегендә һәр көн иртән 9 сәгатьтән кич 9 га кадәр алына.
Казан, Карл Маркс урамы, 68. Телефон 14—93. 37—3—3

ТАТАРСТАН АССР НАРКОМПРОСЫ ЯНЫНДАГЫ
ЧИТТӘН ТОРЫП УКУ ЗУРЛАР МӘКТӘБЕ
5, 6, 7, 8, 9 ҺӘМ 10 нчы КЛАССЛАРГА
УКУЧЫЛАР АЛА
Мәктәп производстводан аерылмыйча үзлегеннән уку юлы белән, тулы булмаган урта һәм урта мәктәп программалары буенча экстерн рәвештә экзамен бирү өчен хәзерләнергә мөмкинлек бирә. Мәктәпкә 16 дан түбән булмаган яштәге кешеләр алыналар.
Читтән торып укучыларга ярдәмгә группалы һәм индивидуаль консультацияләр оештырыла. Уку кирәк-яраклары бирелә.
Гаризалар һәр көн эш сәгатьләрендә 1940 нчы ел 1 нче февральгә кадәр алына.
Гариза белән бергә, керүченең белеме турында документ, хезмәте урыныннан белешмә һәм кабул ителгән үрнәктәге анкета бирелергә тиеш.
Читтән торып уку мәктәбенә керүчеләрдән—5 нче класска керүчеләр рус теленнән һәм арифметикадан, ә башка классларга керүчеләр шул класстан түбәнге классның программасы буенча барлык предметлардан сынаулар үтәләр.
Мәктәптә укудан тукталган кешеләр, укудан тукталуга 3 елдан артык булмаса, сынаусыз алыналар.
Сынаулар 1 нче февральдән, ә укулар 20 нче февральдән башлана.
Адрес: Казан, Кремль, Татнаркомпрос, 5 нче бүлмә. Телефон: Кремль, 22.
Татарстан АССР районнарында торучылар гаризаларны Арча, Әгерҗе, Аксубай, Акташ, Этнә, Акташ, Бөгелмә, Буа, Кукмара, Куйбышев, Лаеш, Мамадыш, Норлат, Минзәлә, Мөслим, Чаллы, Алабуга, Тәтеш, Шөгер һәм Чистай районара консультация пунктларына (урта мәктәпләр янында) бирәләр.
Тулы мәгълүматларны РОНО дан алырга мөмкин.
Дирекция. 2697—3—3

ЭНЕРГОСБЫТ
АБОНЕНТЛАРЫНА БЕЛДЕРӘ:
Реквизитлар (оешманың исме, расчетлар счеты номеры) үзгәрү булса, ул турыда тизлек белән Энергосбытка белдерергә тиеш.
Реквизитлар үзгәрү сәбәпле банкта булуы мөмкин булган аңлашылмаулыклар өчен җаваплылык абонент өстенә төшә. ЭНЕРГОСБЫТ.
2667—2—2

„Спартак" күн комбинаты клапаннар, прокладкалар, бөҗралар, ременнәр, үкчәлекләр, косяклар, коврикләр һәм башкалар өчен 1940 нчы елга күннән, кирзадан, тукылган әйберләрдән һәм башкалардан төрле зурлыкта вак кисәкләр такдим итә.
Производство бүлегендә танышырга мөмкин. Телефон: „Спартак" коммутаторы, 87.
2642—3—2

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
17 нче гыйнварда
КЫЮ КЫЗЛАР
Талон 97.
15 һәм 16 нчы гыйнварда спектакльләр булмый. Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
14, 15 һәм 16 нчы гыйнварда М. Ю. Лермонтовның туууына 125 ел тулуга багышланган юбилей спектакльләре
МАСКАРАД
Бүген талон 77.
Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана.
Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 8 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

„СОЮЗКИШПРОДУКТ"ның
Татарстан бүлеге
Татарстан АССР ның барлык районнарында
ЭЧӘГЕЛӘР
(сыер, сарык, кәҗә, ат, дуңгыз эчәгеләре)
САТЫП АЛА
Эчәгеләрне „Союзкишпродукт" ның җыючы хәзерләүчеләре прейскурант бәясеннән алалар
Гражданнар! Эчәгеләр—дәүләт промышленносты өчен кыйммәтле чимал. Эчәгеләрне ташламагыз һәм әрәм итмәгез, ә аларны „Союзкишпродукт"ның хәзерләүчеләре аркылы дәүләткә сатыгыз.
2618—3—3

АУЧЫЛАР ИГТИБАРЫНА!
1940 нчы ел өчен аучылык свидетельстволары шушы ел 20 нче гыйнвардан 20 нче мартка кадәр спорт җәмгыятьләренең һәм физкультура коллективларының аучылар секцияләрендә бирелә.
Аучылар секцияләре, спорт җәмгыятьләре һәм физкультура коллективлары аучыларга свидетельстволар бирү өчен бланкларны Физкультура һәм Спорт Эшләре шәһәр Комитетыннан алырга тиешләр. Казан, Бауман урамы, 76.
60—1

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Тулысынча яңа программа
Москва 4 нче труппасының гастрольләре
Бөтен труппа катнаша.
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 1 гә һәм кич 5 тән 8 гә кадәр ачык.

Татар Дәүләт Опера театры
Татар Дәүләт Академия театры бинасында
15 нче гыйнварда (талон 63)
КАЧКЫН
Кич 7 сәгать 30 минутта башлана.
11 нче гыйнварга алынган билетлар белән дә кертелә.
Культпоходлар оештыру буенча заявкалар алына.
Телефоннар: 29—04 һәм 30—78.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Тавышлы художестволы яңа фильм ИНЖЕНЕР КОЧИНның ЯЛГЫШУЫ
„УНИОН" 12, 2, 4, 6, 8, 10 да.	УКЫТУЧЫ
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да	Көндезге сеансларда МИТЬКА ЛЕЛЮК Кич УКЫТУЧЫ
„ЧАТКЫ" 6, 8 һәм 10 да.	ҺАВА ПОЧТАСЫ
„ПИОНЕР" 11, 1, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Көндезге һәм Кичке сеансларда СЕНТЯБРЬДӘГЕ ТӨН
„РОТ-ФРОНТ" 10, 12, 2, 4, 6, 8, 10 да.	ЦИРК
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7 һәм 9 да.	БӨЕК ГРАЖДАНИН (беренче һәм икенче сериясе)

Уполн. Главлита ТАССР, № А — 2483 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 187